ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында архив тармагын цифрлаштыру турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Г.З. Габдрахманованың Татарстан Республикасында архив тармагын цифрлаштыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында архив тармагын цифрлаштыру турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты белән берлектә архив эше турындагы законнарга мониторинг ясауны дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыруга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) дәвам итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән берлектә дәүләт архивын (муниципаль архивны) туплау чыганаклары булган оешмаларга республика конкурсларында катнашу һәм дәүләт ярдәме чараларын алу өчен, даими саклана торган архив документларын тәртипкә китерүнең һәм тапшыруның билгеләнгән срокларын үтәү критерийларын исәпкә алып, таләпләр булдырырга.

4. Республика башкарма хакимият органнарына дәүләт ярдәме чаралары буларак бирелгән һәм әлеге дәүләт ярдәме чараларын бирү барышында Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдаланып булдырылган документларны «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә тапшыруны оештыруны һәм тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Республика башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына 2022 елга кадәрге чорга (шул елны кертеп) даими саклана торган архив документларын һәм шәхси состав буенча документларны үз вакытында тәртипкә китерү, шулай ук даими саклана торган архив документларын архив эше турындагы законнарда билгеләнгән сроклар нигезендә дәүләт архивына (муниципаль архивка) тапшыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына дәүләт архивын (муниципаль архивны) туплау чыганагы булып тормаган предприятиеләргә һәм оешмаларга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе яисә муниципаль архив белән архив эше өлкәсендә хезмәттәшлек турында шартнамә төзү мөмкинлеге хакында хәбәр итүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 15 апреле
№ 626-VII ДС